ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОГЫ СОВЕТЫ

КАРАР № 14

Урыссу ш.т.п. 14.12. 2020 ел

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы шәһәр тибындагы Урыссу поселогы Советының “Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәне раслау турында” 2020 елның 14 апреле №4 Карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу поселогында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәсе”нә үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы шәһәр тибындагы Урыссу поселогы Советыныц “Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәне раслау турында” 2020 елның 14 апреле №4 Карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу поселогында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә”не “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 02.03. 2007 ел № 25 ФЗ Федераль законына туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына ярашлы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының 28.04.2020 ел, № 5 карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының « Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районыц Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» 14.04.202020 ел, № 4 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә»сенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. “хезмәт кенәгәсен, хезмәт шартнамәсе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш” 4.1.3. пунктның 4 пунктчасын «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 3 өлешенең 4 пунктына туры китереп бәян итәргә

(пункт 2020 елның 11 августындагы 268-ФЗ номерлы Федераль закон белән гамәлгә кертелгән редакциядә):

«4) хезмәт кенәгәсен һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләрне, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш.»;

1.2. «Хезмәт шартнамәсе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш, мәҗбүри пенсия иминиятенең иминият таныклыгын» 4.1.3 пунктының 6 пунктчасын «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законныц 16 статьясындагы 3 өлешенең 6 пункты (2020 елның 19 июнендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон белән гамәлгә кертелгән редакциясендә) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш.»;

1.3. 8.1.1 пунктның 4 пунктчасын «4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясындагы 4 пункты нигезендә (2020 елның 11 августындагы 268-ФЗ номерлы федераль закон белән гамәлгә кертелгән редакциясендә) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар формалаштыру һәм әлеге мәгълүматларны мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персональләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен бирү.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында **http://pravo.tatarstan.ru** адресы буенча бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә **http://jutaza.tatarstan.ru** веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу поселогы Советының кеше хокуклары, законлылык һәм хокук тәртибе буенча комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр тибындагы Урыссу поселогы Башлыгы -
шәһәр тибындагы Урыссу поселогы Советы Рәисе А. Ә. Шәфигуллин